ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

«03» апреле 2024 ел Кече Шилнә авылы № 113

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге составына керүче Белоус авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 9 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 16 ноябрендәге 10 номерлы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Белоус авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Белоус авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Кече Шилнә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Советының 2019 елның 29 декабрендәге 9/2 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге составына керүче Белоус авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 9 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 16 ноябрендәге 10 номерлы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Белоус авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апреле 13.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге составына керүче Белоус авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 9 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт территориясен төзекләндерү;

-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту»;

2) 1 пунктның икенче-өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 16 ноябрендәге 10 номерлы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Белоус авылында гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт территориясен төзекләндерү;

-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту»;

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Кече Шилнә авыл җирлеге, Белоус авылы, Центральная ур., 16А йорт (мәйданда).

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Кече Шилнә авыл җирлеге Башлыгы А.Г. Даутов